**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чемодурово авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чемодурово авылы №45 13.04.2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 сентябрь номерлы карары белән расланган, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чемодурово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 27 март 86 номерлы карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указы , Азнакай шәһәр прокуратурасының 2022 елның 10 мартындагы 02-08-02/2022 номерлы протесты нигезендә

Чемодурово авыл жирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 сентябрь 86 номерлы карары белән расланган, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чемодурово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 27 март 86 номерлы карар редакциясендә) 3 пукнтның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу

өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) хезмәткәрнең (эшченең) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.http://pravo.tatarstan.ruhttp://aznakayevo.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Н.Б.Котельникова